**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "49-нчы санлы гомуми үстерелешле балалар бакчасы" муниципаль үзидарә мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе**

# «Чык тамчысы»

№1

Сентябрь, 2022 нче ел

## 1 нче сентябрь-белем бәйрәме



Туган илнең һәр шәһәрендә, районында, авылында 1 нче сентябрь - Белем бәйрәмен каршы алдылар. Белем бәйрәме - кеше тормышындагы иң зур, дулкынландыргыч һәм шул ук вакытта күңелле дә бәйрәмнәрнең берсе. Бала өчен тәрбияче әти-әни, яшәгән өй шикелле якын булганда гына бала теләп бакчага бара. Ә ата-ана өчен кечкенә сабыйның үзе киенеп-җыенып бакчага баруы һәм бер мәшәкатьсез калуы – зур куаныч, озын көнгә яхшы кәеф. Ул гына да түгел, сезнең яшьлек-матурлык, үз-үзегезне гел шулай гүзәл йөртүегез дә безне куандыра. Чөнки сабыйлар сездәге ямьне, гүзәллекне күреп үсәләр, шуңа ияләшәләр, үзләренә шундый талэп куялар, матурлыкка омтылалар. Кадерле балалар бакчасы хезмәткәрләре! Бүген барыбыз өчен дә зур бәйрәм. Сезгә яңа һәнәри уңышлар һәм иминлек телим! Бары бәхетләр, уңышлар һәм иҗади биеклекләр сезгә.

Безнең балалар бакчасының мэктәпкә әзерлек төркеменә йөрүче балалар 7 нче мәктәпкә тантаналы линейкага бардылар.Алар анда беренче класста укучы дусларын курделәр.Балаларыбыз мәктәптән бик зур куанычлар,якты өметләр баглап кайттылар. Без балаларга мәктәкә карата уңай караш тәрбияләүебез белән бик шат.

Һава салкыная бара,
Аяк басабыз көзгә.
Сары төстә яфраклар да
Чалына инде күзгә.
Хушлаштык ямьле җәй белән,
Үтте дә каникуллар.
Бүген бәйрәм – белем көне,
Мәктәпкә илтә юллар.

## «Татарстан кроссы-2022»




17 нче сентябрьда безнең шәһәрдә “Татарстан кроссы-2022” булып үтте.Кросс кешеләр тормышында мөһим роль алып торуын тагын бер кат исбатлады.”Татарстан кроссы-2022” кояш нурлары астында балкып торган Түбән Кама шәһәренең предприятие хезмәткәрләрен,мәктәп укучыларын,укытучыларны,тәрбиячеләрне үзенә җыйды.”Татарстан крроссы”нда катнашу купләр өчен үзмаксат тугел,ә спорт сыйфатларын,физик көчне курсәтү.Безнең тәрбиячеләребез Ахметшина Нәфисә һәм Нигъматуллина Ләйлә кроссета катнаштылар.Алар яхшы кәеф һәм энергия туплап кайттылар.

## «Профсоюз тормышы»

Татарстан республикасында 22 нче сентябрьдан профсоюз дәресләре белән җиде көнлек марафон башланып китте. Җиде ел рәттән узучы бу марафон барлык мәктәпләрдә,колледжларда,балалар бакчасында якты вакыйга булып истә кала.Бу җиде көнлектә төрле мастер класслар,мавыктыргыч экскурсияләр булды.Бу атналык 27 нче сентябрь көнне профсоюз диктанты белән тәмамланды.Бу чаралардан бездә читтә калмадык.Профсоюз рәисе Шакирянова Айзира Фәсхетдин кызы мастер класслар һәм башка бик кызыклы чаралар үткәрде.








## Туган көнең белән Түбән Кама!

22 нче сентябрь көнне шәһәребез үзенең туган көнен билгеләп үтте. 1966 нчы елның шушы көнендә Түбән Кама эшчеләр поселогына шәһәр статусы бирелә. Бу көнне шәһәр күләмендә төрле бәйрәм чаралары уздырылды. Безнең балалар бакчасы тәрбиячеләре төркемнәрдә шәһәребез тарихы, аның истәлекле урыннары турында әңгәмәләр оештырдылар. Матур шигырьләр укылды. Шәһәребезне бездә матур бәйрәме белән котлыйбыз. Шәһәребез чәчәк атсын, даны еракларга таралсын дигән теләктә калабыз,

Якты булыр синең киләчәгең,
Кичәгедән матур бүгенең.
Горурлыгы булсаң зур илемнең
Син йолдызы - татар күгенең.

## Тәҗрибә уртаклашабыз

Һәр кешенең туган җире була. Һәм һәр бала аның нәрсә икәнен белеп үсәргә тиеш. Шуңа күрә бу эшне кече яшьтән үк балалар күңеленә сала башларга кирәк.

Безнең төркемдә кече яшьтәге балалар булуга карамастан, алар үзләренең Түбән Кама шәһәрендә яшәүләрен белергә, киләчәктә дә туган шәһәрләре белән горурланырга тиешләр. Әйе, безнең шәһәребез – Түбән Кама елдан –ел төзекләнә, матурая бара. Әйтерсең лә кояш та безнең шәһәребез өстендә ныгырак балкый, җылы нурларын сибә.

Без, тәрбиячеләр, балалар белән әңгәмә вакытында шәһәребез турында белемнәрен арттырабыз, өстәмә мәгълүмат бирәбез. Шәһәребездә бик күп ял урыннары – парклар, музейлар, кино заллары һәм башкалар. Шәһәребез үзенең табигате, яшеллеге белән күпләрнең күңелен җәлеп итә. Мәсәлән: җәйге эссе көннәрдә, шәһәр читендә генә урнашкан, борма – борма булып аккан Чулман елгасы буенда күпләр ял итә, җанына , тәненә сихәт ала, суларында коена, комнарында кызына. Кояшлы алан паркында балалар һәм өлкәннәр өчен дә бик күп ял урыннары, спорт белән шөгелләнү мөмкинлекләре урнаштырылган...Санап китсәң бик күп.

Минемчә, беренче чиратта, Түбән Каманың табигате турында сөйләргә кирәк. Әти – әниләр баланы бакчага алып барганда, кайтканда бакчаның нинди матур җирдә урнашуына басым ясасалар, аларның хәтерендә бу мәгълүмат тирәнрәк урын алыр иде. Һәм без, тәрбиячеләр әти – әниләр белән бердәм эшләргә, шулай эшләгәндә генә балаларда ихтибарлылык, мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык, һ.б сыйфатларны тәрбияләп үстергәндә генә һәр балада, һәр кемдә җимешен күрә алабыз. Шәһәребезгә мәхәббәт белән бергә матурлыкны күрергә, тоярга, әңгәмәләр ярдәм итә. Ата –аналар балалары белән Лемаев мәйданында, җиңү мемориалы, Г. Тукай, М. Җәлил һәйкәле, мәчет – чиркәүләр, Гаилә, Нефтчеләр, Кояшлы алан һ.б. урыннарда әңгәмә алып барса бигрәк тә яхшы. Бәйрәм вакытларында төрле милләт кешеләре,аларның гореф – гадәтләре белән якыннан танышалар, якынаялар. Бер – берсе белән дуслашалар, аралашалар. “ Бердәмлек” – дигән төшенчәнең мәгънәсенә тирәнтен төшенәләр.

Шулай ук без, тәрбиячеләр бакчабызда да зур эш алып барабыз. Бакчабызда инде күп еллар буена эшләп килүче” Халкым мирасы” дип аталган музеебыз эшли. Музейга балалар бик теләп йориләр. Балалар гына түгел эти – әниләр дә зур кызыксыну белән чараларда катнашалар. Чөнки хәзерге яшь эти – әниләр таныш булмаган әби – бабаларыбызның тормышын,эш коралларын, бишек, өс киемнәрен, бизәнү, уен кораллары, һ.б.экспонат белән якыннан танышалар, тотып карыйлар. Балалар һәм эти – әниләр белән берлектә, күмәк җырлы – биюле уеннар да уйныйбыз, бишек җырларын җырлыйбыз, тыңлыйбыз бик шатланып. Шулай ук шөгыльләрдә, саф һавада, һәр бәйрәмдә халкыбызның төрле уеннары, җырлары белән үрелеп бара.

Сүземнең ахырына җиткәндә, шуны әйтәсем килә...Балаларга кечкенәдән биргән белем – тәрбияне, ботен ил халкы да үзгәртә алмый. Кечкенә генә бер бөртек орлыкны җиргә күмгәч, аңа нинди игътибар, хезмәт кирәклеген җимешен күреп, татыгач кына аңлыйсың. Шуңа күрә бу урында халкыбызның бер мәкале искә төшә: “ Хезмәт төбе – хөрмәт!”. Менә шушыны балалар күңеленә эти – әниләр белән берлектә сабыйларыбызда күрергә язсын дигән теләктә калам.

Зәңгәр Чулман буйларында
Үсеп чыкты бер кала.
Ул безнең кояшлы калабыз,
Ул безнең Түбән Кама.

**Самиева Минзилә Давлетовна**
**1 нче категорияле тәрбияче.**

## 27 нче сентябрь - мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү хезмәткәрләре көне

Хөрмәтле тәрбиячеләр, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре һәм ветераннары! Сезне чын күңелдән һөнәри бәйрәмегез белән тәбрик итәбез. Бу өлкәдә балаларны ихлас яратучы, хәстәрлекле кешеләр эшли. Игелекле хезмәтегез, һөнәргә тугры булуыгыз, балаларны тәрбияләү эшендәге уңышларыгыз өчен ихлас рәхмәтебезне белдерәбез. Сезгә ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге телибез. Сез хезмәт куйган җирдә балаларның шатлыклы авазлары һәрчак яңгырап торсын! 23 нче сентябрьда халыклар иҗаты йортында шушы бәйрәмгә багышланган чара үтте.4 нче төркем тәрбиячесе Нигматуллина Ләйлә Рамиль кызын тантаналы рәвештә яшь белгечләр составына алдылар. Аның остазы-Самигуллина Айсылу Рафаэль кызы. Ә шеф повар Киселева Татьяна Виктор кызын мактау грамотасы белән бүләкләделәр.Котлыйбыз!Эшләрендә уңышлар теләп калабыз!

 



## Өлкәннәр көне белән!

Илебез буенча 1 нче октябрьда Өлкәннәр көне билгеләп үтелә.Төрле җирләрдә хөрмәтле өлкәннәребезне котлаулар,бүләкләр белән искә алабыз.30 нчы сентябрьда безең балалар бакчасында эшлүче өлкән яшьтәге хезмәткәрләәребезне хөрмәт йөзеннән котлап үттек.Бу көнне без аларга үзебезнең рәхмәтләребезне җиткердек.

Сезнең тормыш юлы матур тарих,
Күпләр өчен үрнәк булырлык.
Рәхмәт, дибез, сезгә чын йөрәктән,
Сезнең гомер — безнең горурлык.
Өлкәннәр көне белән хөрмәтле хезмәттәшләребез!
Сез безгә үрнәк!Сез безгә терәк!

## Әти-әниләр сезнең өчен!

Якын кешеләр баланы тәрбияләгәндә зур роль уйныйлар. Балаларга якын кешеләре ярдәмче булырга тиеш. Хөрмәтле әти-әниләр, балаларга карата түземле булыгыз! Беркайчан да үз балагызны башка бала белән чагыштырмагыз!

1. Өйрәтәсе килгән эшне балага күрергә рөхсәт итегез. Үзе эшли ала торган эшне аның өчен эшләмәгез.
2. 2,5 -3 яшьтәге бала үзе чишенә ала, һәм кайсыбер киемнәрен үзе кия ала. Аларның эч киемнәрен, аяк киемнәрен, кофта, чалбарларын киергә хәлләреннән килә. Ә менә замокларын, төймәләрен эләктерергә аларга инде без, олылар булышабыз. Өйрәткәндә ашыгырга ярамый. Буш вакытыгыз булганда гына өйрәтегез. Баланы ашыктырсагыз, ул өйрәнгән эшен башка кабатларга теләмәскә мөмкин.
3. Баланы мактау файдага бара. Сез “рубашкаңны дөрес кимәгәнсең”, “чәчеңне матур тарамагансың” , “чалбарыңны дөрес кимәгәнсең” дип шелтә белдереп торсагыз, баланың үз-үзенә ышынычы бетәргә мөмкин. Дөрес булмаса да, ул аны үзе эшләгән. Мактагыз да, бик кирәк булса, дөресләп куегыз.
4. Балалар бакчасында тәрбияләнгән культура-гигиена күнекмәләрен ныгыту – ата-аналарның төп бурычы! Үз балаларыгызга үрнәк булыгыз, бу күнекмәләрне үтәгез!

***Газета 49 нчы балалар бакчасы тәрбиячеләре Ахметшина Нәфисә Шакирҗан кызы һәм Бадертдинова Резедә Рәис кызы тарафыннан чыгарылды.***